ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БИШНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БИШНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**15 июль 2025 ел** Бишнә ав. **№ 81**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә терекөмешле лампаларны туплау урынын булдыру, кулланучыларга аның урнашуы турында мәгълүмат бирү турындгы 2023 елның 24 мартындагы 13 номерлы Бишнә авыл җирлеге башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт экология мониторингы (әйләнә-тирә мохитнең дәүләт мониторингы) турында Нигезләмәне раслау хакында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 14 мартындагы 300 номерлы карары нигезендә Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә терекөмешле лампаларны туплау урынын булдыру, кулланучыларга аның урнашуы турында мәгълүмат бирү турындагы 2023 елның 24 мартындагы 13 номерлы Бишнә авыл җирлеге башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«4. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә эшкәртелгән терекөмешле лампалар туплану урынының урнашуы турында мәгълүматны әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштыру юлы белән кулланучыларга хәбәр итәргә.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру (http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында: Бишнә авылы, Үзәк урамы, 5 (Советның административ бинасы), Бишнә авылы, Школьная урамы, 10 (Бишнә авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Бишнә авыл җирлеге башлыгы:** **И.М.Фатхуллин**